**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XIV УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 24**

Шуган ав. 16 июль 2021 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Шуган авыл җирлеге Советының 21.09.2020 ел № 4 карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе, Шуган авыл җирлеге Уставы нигезендә, Шуган авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү, җир эшләрен җитештерүгә рөхсәтләр бирү буенча төзекләндерү өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен бирергә.

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Советына карау өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә Мөслим муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә соңга калмыйча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзүгә Як булып чыгарга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән соң үз көченә керә.

6. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Шуган авыл җирлеге башлыгы** **Басорина А.Ю.**